ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№311 от «24» 09 2021 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 4 февралендәге «Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы муниципаль белем бирү
оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми,
урта гомуми белем бирү программалары
буенча укырга кабул итүне оештыру турында»
43 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2021 елның 27 августындагы 02-08-02-2021 санлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законга таянып (02.07.2021 елгы редакциядә), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүне оештыру турында» 43 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 10 пунктның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча бертуган яки эти яки әниләре төрле булган ир һәм (яки) кыз туганнары белем ала торган дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасына укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия».

2. Әлеге карарны «Интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары М.Р. Хуҗаҗановны билгеләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов